ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

Х. Такташа ул., 94, а/я 44, Казань, 420107

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮ, ӘЙЛӘНЕШЕ
ҺӘМ СЫЙФАТЫ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ
КОНТРОЛЕН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
КУЛЛАНУЧЫЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН
ЯКЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь
инспекциясе)

Һ.Такташ урамы, 94 нче йорт, Казан шәһәре, 420107

тел. (843) 278-92-00, факс (843) 278-91-92, e-mail: gosalcogol@tatar.ru, http://gosalcogol.tatar.ru,
ОКПО 42151664, ОГРН 1021602865239, ИНН/КПП 1654025044/165901001

# БОЕРЫК

12.10.2023 Казан ш. № 10-07/119

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 2018 елның 19 апрелендәге 12-07/60 номерлы боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең ведомство бүләкләре турында» ведомство бүләкләре белән бүләкләү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны законнарга туры китерү максатыннан боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 2018 елның 19 апрелендәге 12-07/60 номерлы боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең ведомство бүләкләре турында»гы ведомство бүләкләре белән бүләкләү Тәртибенә (2023 елның 13 мартындагы 10-07/32 номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) үзгәрешләр кертергә:

1 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3 пунктның дүртенче абзацында «ведомстволар» сүзен «Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе» дигән сүзләр белән алмаштырырга;

9 пункттта «ведомстволар» сүзен «Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе» дигән сүзләр белән алмаштырырга

2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең административ һәм суд практикасы бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең коррупцион һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазыйфаи затка әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Җитәкче** **Җ.Й. Әхмәтханов**